ҖОМГА
29 МАРТ
1940 ел
№ 73 (5873)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Казан, Матбугат йорты. ТЕЛЕФОННАР: экономик һәм культура бүлекләре 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

БОЛЬШЕВИК ЯЗУЧЫ

Татар совет әдәбиятының алдынгы вәкилләреннән берсе булган Шәриф Камалның әдәби һәм җәмагать эшчәнлегенә утыз ел тулды. Республикабызның хезмәт ияләре бу тарихи датаны зур күтәренкелек белән билгеләп үтәләр.

Большевик язучының иҗади юлы гаять катлаулы һәм күркәле. Ул үзенең иҗади эшен элекке Россиянең коточкыч авыр шартларында башлап җибәрде. Аның үткен һәм ялкынлы каләме Россиядә реакциянең котырынган елларында, интеллигенция арасында черек таралу һәм төшенкелек аеруча көчәйгән елларда тирбәлә башлады һәм демократик юл белән туктаусыз үсүендә дәвам итте. Һәр вакыт яңа, яңалыкка омтылу, тормышны реалистик нигезләрдә чагылдыру һәм искелекне рәхимсез рәвештә фаш итү, аерым этапларда эпопеяләре юмор, сатира аркылы оста итеп бирә белү—менә болар барысы да атаклы язучының иҗади юлында күркәле сыйфатлар булып торалар.

Шәриф Камал иҗадының бер өлеше Октябрь революциясенә кадәрге чорга туры килә. Ул матбугатка 1910 нчы елларда ук килнаша башлый. Ләкин, патша Россиясенең авыр тормышы яш әдипкә үсәргә мөмкинлек бирми. Аның прогрессив адымнары һәр җирдә җиңди каршылыкка очрыйлар. Патша монархиясенең лакейлары булган буржуаз милләтчеләр яш язучының һәрбер адымын күзәтәләр һәм аны әдәбият дөньясыннан читләштерү өчен бөтен чараларны күрәләр. Бу бик табигый. Чөнки капитализм өчен, татар буржуазиясе өчен демократ язучылар түгел, бәлки реакцион язучылар кирәк. Искелекне мактаучы, эксплоатацияне яклаучы, һәр төрле кыргыйлыкны аклаучы сәләтле булган кешеләр кирәк. Менә шуңа күрә дә буржуазия һәм аның ялчылары булган милләтчеләр демократ язучыларны, прогрессив кешеләрне эзәрлекләделәр, аларны тормыш төбенә кудылар. Рус халкының бөек шагыйрьләре М. Ю. Лермонтов, А. Пушкин һәм татар халкының сөекле шагыйре Г. Тукайлар—элекке тормышның әнә шундый корбаннары булдылар.

Яңалыкны сөюче һәм яңалыкны яклаучы Ш. Камал өчен Бөек Октябрь Социалистик революциясеннән соң киң юл ачылды, үзенең прогрессив фикерләрен киң җәелдерү өчен тулы шартлар туды. Һәм бу аңлаешлы да. Чөнки безнең партиябез, бөек юлбашчыбыз Ленин һәм Сталин революциянең беренче көннәреннән үк халык иҗаты һәм аны үстерү һәм киңәйтү турында зур кайгыртучанлык күрсәттеләр. Пролетар революциясе [illegible] барган саен бу шартлар киңәйделәр һәм яңа талантлар турында кайгырту, аларны тәрбияләү, үстерү мәсьәләсе дәүләт эше булып әверелде. Шәриф Камал боларның барсын да бу вакытта күрде һәм революциянең беренче көннәреннән үк Советлар байрагы астына басты.

Шәриф Камал карт большевикларның берсе. Ул, ВКП(б) сафларына 1919 нчы елны керде. Бик ачык ки, ул еллардан соң партия эчендә төрле тайпылышлар булды, партиягә үтеп кергән дошман элементлар ВКП(б) сафларын эчтән таркатырга, аны генеральный юлдан читкә этәрергә маташтылар. Бу маташу бер яктан фракцияләр, группировкалар аркылы алып барылган булса, икенче яктан матур әдәбият аркылы алып барылды. Троцкийлар, буржуаз милләтче „язучылар" үзләренең „әсәрләре" аркылы партия политикасын бозып күрсәтергә маташтылар. Ләкин Шәриф Камал мондый тайпылышлардан ерак торды, ул нык рәвештә партиянең генеральный юлыннан барды һәм үзенең тирән эчтәлекле, художество ягыннан югары торган гүзәл һәм үткен әсәрләре белән халык дошманнарын фаш итәргә булышлык күрсәтте.

Аның „Ут" кебек, „Томан арты" һәм „Матур туганда" кебек атаклы әсәрләре партиябез тарафыннан алып барыла торган бөек эшләрне массага художество теле белән сөйләп бирә торган, аңлата һәм пропагандалый торган әсәрләр, халык дошманнарының мәкерле эшләрен күрсәтә торган һәм аларны фаш итәргә өйрәтә торган әсәрләр булып торалар. Большевик язучы буларак Шәриф Камал үзенең бу әсәрләрендә һәм башка күп кенә әсәрләрендә гаять зур оештыручылык, пропагандистлык һәм агитаторлык үрнәкләрен бирде һәм шуның белән ул массаларны коммунизм өчен көрәш фронтына туплау буенча партиягә зур ярдәм итте.

Ш. Камал партия һәм хөкүмәт тарафыннан үткәрелә торган чараларның һәм социализм төзелеше өлкәсендә булган җиңүләрне үз вактында күрүче, аларны матур әдәбият аркылы массага үз вактында җиткерүче язучыларның берсе. Ул үзенең иҗади тормышында бик күп оригинальлеге белән бик күп язучылардан, драматурглардан аерылып тора. Ул, бөек юлбашчыбыз иптәш Сталинның: „Большевиклар халыкның киң массасы белән элемтәләрен саклаган вакытта, алар җиңелмәслек булачаклар" дигән күрсәтмәләрен һәр вакыт исендә тотып эш итте. Коммунист, реалист язучының большевистик сыйфатлары әнә шундый.

Билгеле, бу сыйфатлар атаклы язучыга үзлегеннән-үзләре килмәделәр. Аңда бу гүзәл сыйфатларны безнең данлыклы партиябез, Ленин—Сталин партиясе тәрбияләде. Ш. Камалның сыйфатларын безнең яшь язучыларыбыз нык өйрәнергә һәм үзләштерергә, гадилек һәм тирән идеялелек үрнәкләрен үзләренә күчерергә тиешләр.

Ш. Камал үзенең 30 еллык әдәби һәм җәмагать эшчәнлеге чорында бик күп санлы һәм тирән эчтәлекле, художество ягыннан югары дәрәҗәдә әсәрләр бирде. Моның белән безнең халкыбыз урынлы рәвештә мактана һәм горурлана. Шуның белән бергә, хәзер бөек хезмәт ияләре большевик язучыдан тагын да яхшырак һәм күркәлерәк әсәрләр көтәләр. Коммунизм өчен көрәшүче һәм [illegible] торучы [illegible] халык бәхете өчен армый-талмый эшләүче атаклы художник—Шәриф Камал киләчәктә дә үзенең иҗади эшен туктаусыз дәвам итерер һәм татар совет әдәбияты хәзинәсен яңа классик әсәрләр белән тагын да баетыр.

Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләреннән СССР Верховный Советына сайлауларның нәтиҗәләре турында белдерү

(Сайлауларның нәтиҗәләре турындагы саннар Союз Советына һәм Милләтләр Советына сайлаулар буенча округ сайлау комиссияләреннән СССР Верховный Советы Президиумы секретариатына алынган материаллар буенча иглан ителә)

1940 нчы елның 24 нче мартында Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләрендәге сайлау округлары буенча СССР Верховный Советына сайлаулар үтте.

СССР Верховный Советына сайлауларны үткәрү өчен Украина ССР ның көнбатыш өлкәләрендә Союз Советына сайлаулар буенча 27 сайлау округы һәм Милләтләр Советына сайлаулар буенча 6 сайлау округы, Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләрендә Союз Советына сайлаулар буенча 16 сайлау округы һәм Милләтләр Советына сайлаулар буенча 6 сайлау округы төзелгән иде.

Сайлаулар Союз Советына сайлаулар буенча 43 сайлау округының барсында да һәм Милләтләр Советына сайлаулар буенча 12 сайлау округының барсында да үткәрелде.

Тавыш бирү Союз Советына һәм Милләтләр Советына сайлаулар буенча гомуми булган сайлау участкыларында үткәрелде. Барлыгы 10.387 сайлау участкысы төзелгән иде, шулардан: Украина ССР ның көнбатыш өлкәләрендә—6.729 участкы, Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләрендә—3.658 сайлау участкысы.

Округ күләмендәге сайлау комиссияләре СССР Верховный Советына барлык 55 депутатның сайлануын теркәделәр. Сайланган депутатлар барсы да коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатлары.

Сайлаучылар исемлекләре буенча барлыгы 7.966.923 сайлаучы теркәлгән иде. Союз Советына сайлаулар буенча тавыш бирүдә 7.894.971 кеше, яки теркәлгән сайлаучыларның гомуми санының 99,09 проценты һәм Милләтләр Советына сайлаулар буенча—7.895.861 кеше, яки 99,10 процент катнашты.

Союз Советына сайлаулар буенча 43 сайлау округының барсында да коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатлары өчен 7.743.210 кеше тавыш бирде, бу—тавыш бирүдә катнашкан барлык сайлаучыларның 98,07 проценты. „СССР Верховный Советына сайлаулар турында положение" нең 90 нчы статьясе нигезендә, дөрес түгел дип табылган бюллетеннәр—8.132. Кандидатларның фамилияләре сызылган бюллетеннәр—143.629.

Милләтләр Советына сайлаулар буенча 12 сайлау округының барсында да коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатлары өчен 7.743.965 кеше тавыш бирде, бу—тавыш бирүдә катнашкан барлык сайлаучыларның 98,07 проценты. „СССР Верховный Советына сайлаулар турында положение" нең 90 нчы статьясе нигезендә, дөрес түгел дип табылган бюллетеннәр—8.955. Кандидатларның фамилияләре сызылган бюллетеннәр—142.941.

		Сайлауларда катнашты				Коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатларына тавыш бирде			
		Союз Советына		Милләтләр Советына		Союз Советына		Милләтләр Советына	
	Сайлаучылар саны	Абсолют сан	Сайлаучылар санына карата процентлар белән	Абсолют сан	Сайлаучылар санына карата процентлар белән	Абсолют сан	Тавыш бирүдә катнашканнар санына карата процентлар белән	Абсолют сан	Тавыш бирүдә катнашканнар санына карата процентлар белән
Украина ССР (көнбатыш өлкәләр)	5.036.295	4.987.318	99,03	4.985.041	98,98	4.890.317	98,06	4.887.953	98,05
Белоруссия ССР (көнбатыш өлкәләр)	2.930.628	2.907.653	99,21	2.910.820	99,32	2.852.893	98,11	2.856.012	98,11
Барлыгы:	7.966.923	7.894.971	99,09	7.895.861	99,10	7.743.210	98,07	7.743.965	98,07

ЯЗУЧЫ ШӘРИФ КАМАЛГА

ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты һәм хезмәт ияләре депутатларының Казан Шәһәр Советы Башкарма Комитеты Сезнең әдәби-җәмагат эшчәнлегегезнең 30 еллыгы көнендә Сезгә—татар совет әдәбиятының күрнекле вәкиленә ялкынлы сәламнәрен һәм кайнар котлауларын җибәрәләр. Һәм Сезнең озак еллар яшәвегезне һәм иҗад итүегезне телиләр.

Сез утыз ел эчендә эксплоататорларга каршы, буржуаз милләтчеләргә һәм барлык реакцион көчләргә каршы нәфрәт һәм килешмәүчән көрәш рухында һәм коммунизм идеяләренә чын күңелдән бирелгәнлек рухында хезмәт ияләре массасын тәрбияләүче югары художестволы күп кенә гүзәл әсәрләр иҗад иттегез.

Сезнең 30 еллык юбилеегез көнендә озак еллар яшәвегезне һәм иҗад эшегездә яңа гүзәл уңышларга ирешүегезне телибез һәм большевик язучы дигән почетлы исемне киләчәктә дә намус белән акларсыз дип тулы ышаныч белдерәбез.

Яшәсен Ленин—Сталин милли политикасы!

Яшәсен халыкларның бөек юлбашчысы иптәш **Сталин!**

ВКП(б) НЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЫ. ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ.

⁂

Бөтен халык катнашы белән үткәрелә торган 30 еллык әдәби иҗад юбилееӊ көнендә Сезне—шаулап чәчәк атучы әдәбиятыбызның якты тантанасын, совет халкының сөекле язучысын чын күңелдән котлыйбыз.

Сез безгә—совет әдәбиятының алтын фондына кергән югары художестволы большевистик әсәрләрегез белән намуслы эш үрнәкләре бирдегез.

Сез безгә—һәрбер талантны кадерләп үстерүче сөекле юлбашчыбыз бөек Сталин әйткәнчә—кеше рухының инженеры булу өчен кирәкле сыйфатларны гәүдәләндереп күрсәттегез.

Сез, иптәш Сталин тарафыннан язучылар алдына куелган тормыш чынлыгын чагылдыру юлындагы иҗад бурычларын киң художество полотноларыгызда — романнарыгызда, пьесаларыгызда һәм хикәяләрегездә үтәп килдегез.

Без Сезнең озак еллар яшәвегезне телибез. Без Сезнең, Ленин—Сталин партиясе җитәкчелегендә коммунизм өчен барган тарихи көрәшләр турында, бөек җиңүләр аркылы матурлана, күңелләнә барган бәхетле тормышыбыз турында, искиткеч гүзәл заманыбызның данлы геройлары турында бик күп яңа әсәрләр иҗад итүегезгә нык ышаныч белдереп, 30 еллык намуслы эш бәйрәмегезне котлап, кулыгызны кысабыз.

ТАТАРСТАН СОВЕТ ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ.

ШӘРИФ КАМАЛ (БАЙГИЛЬДИЕВ) ИПТӘШ.

Большевик язучы Шәриф Камал (Байгильдиев) иптәшкә

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты Сезне—атаклы татар совет язучысын әдәби һәм иҗтимагый эшегезнең данлыклы 30 еллыгы белән кайнар рәвештә котлый.

Сезнең бик урынлы рәвештә татар әдәбиятының алтын фондына кергән әсәрләрегезне Татарстан хезмәт ияләре генә түгел, бәлки Ватаныбыздагы башка кардәш халыклар да укыйлар, яраталар һәм югары бәя бирәләр. Сезнең халыклар массасына якын булган иҗадыгыз хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләүнең бөек эшенә, сөекле Ватаныбызның халыкка һәм Ленин—Сталин партиясенә чын күңелдән бирелгән патриотын—яңа совет кешесен тәрбияләү эшенә ярдәм итә. Капитализм заманындагы коллык һәм изү турындагы, гражданнар сугышының утлы еллары турындагы, шәһәрдә һәм авылда социалистик төзелеш геройлары турындагы реалистик әсәрләрегездә хезмәт ияләре үзләренең тормышларын күрәләр, кешелекне азат итү өчен, халык бәхте өчен үз аталарының һәм туганнарының көрәшләрен күрәләр.

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты Сезнең йөзегездә татар әдәбиятының реалистик мәктәбен төзүчеләрнең берсен, иҗады интернационализм идеяләре белән, пролетар революция идеяләре белән, коммунизм идеяләре белән сугарылган зур художник-гуманистны котлый.

Бөек Ватаныбыз файдасына Сезгә киләчәктә дә нәтиҗәле эш телибез һәм татар совет әдәбиятының үсүе һәм чәчәк атуы өчен Сезнең әле күп нәрсәләр эшләячәгегезгә ышанабыз.

ВКП(б) НЫҢ ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ.

⁂

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Сезне әдәби һәм җәмагать эшегезнең 30 еллык юбилее белән чын күңелдән котлый.

Орденлы республикабызның хезмәт ияләре Сезнең язучы, драматург һәм журналист булып хезмәт ияләре массасын тәрбияләү эшендә гаять зур роль уйнаган күп яклы эшегезне горурлык белән билгеләп үтәләр.

Формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик татар культурасы тарихында Сезнең исмегез мактаулы урында тора.

Данлыклы юбилеегез көнендә Сезне котлап, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Сезгә Ватаныбыз файдасына, социалистик культураның чәчәк атуы өчен күп еллар буена уңышлы иҗад эше тели.

ТАТАРСТАН АССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ.

⁂

Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы Сезнең әдәби иҗад эшегезнең 30 еллыгы көнендә Сезне кайнар рәвештә котлый.

Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы, формасы белән милли һәм эчтәлеге белән социалистик культураны үстерү эшендә Сезнең эшегезнең зур әһәмияте барлыгын күрсәтү белән бергә, Сез киләчәктә дә Сталин эпохасына лаеклы булган яңа әсәрләр тудыру өстендә тагын да зуррак энергия белән эшләрсез дип ышана.

Сезгә сәламәтлек, озак гомер һәм иҗад эшегездә тагын да уңышлар телибез.

ТАТАРСТАН АССР СОВНАРКОМЫ.

⁂

Кадерле иптәш Шәриф Камал!

ВЛКСМ ның Татарстан Өлкә һәм Казан шәһәр комитетлары Сезне 30 еллык әдәби иҗад һәм иҗтимагый юбилеегез белән котлыйлар.

Орденлы республикабызның яшьләре, Сезнең әсәрләрегезне зур кызыксыну белән укып, алардан социалистик Ватаныбызга, коммунистлар партиясенә һәм бөек Сталинга чиксез мәхәббәт хисләре, безнең бәхетле яшь буыныбыз яши торган һәм эшли торган хисләрне—совет патриотизмы хисләрен һәм халык дошманнарына карата килешмәүчәнлек хисләрен табалар.

Сезнең әсәрләрегезнең яшьләребезне художество ягыннан тәрбияләүдә дә зур әһәмияте бар. Алар—югары дәрәҗәдәге осталык иҗадлары. Сезнең талантыгыз—Октябрьгә кадәрге классик әдәбиятны безнең совет әдәбиятының иң яхшы үрнәкләре белән бергә бәйли торган җанлы буын.

Сезне иҗад уңышларыгыз белән котлап, без Сезгә сәламәтлек һәм бөек социалистик Ватаныбыз файдасына озак еллар буена нәтиҗәле эш телибез.

ВЛКСМ НЫҢ ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ.

⁂

30 еллык юбилеегез көнендә, Сезгә, Шәриф ага,—татар совет әдәбиятының күренекле классигына, үткен каләмле публицистка һәм күрнекле җәмагат эшлеклесенә,—ялкынлы большевистик сәлам!

Данлыклы Ватаныбыз, бөек совет халкы, бөек Ленин—Сталин партиясе өчен, формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик культураны тагын да үстерү юлында Сезнең киләчәктә дә матур һәм сөелеп укыла торган әсәрләр бирүегезне, барлык хезмәт ияләре файдасына озак еллар яшәвегезне телибез.

„КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН" ГАЗЕТАСЫ КОЛЛЕКТИВЫ.

Ш. КАМАЛ ИПТӘШНЕҢ 30 ЕЛЛЫК ИҖАД ЮБИЛЕЕ УҢАЕ БЕЛӘН КИЛГӘН КОТЛАУ ТЕЛЕГРАММАЛАРЫ

Әрмәнстан язучылары прозаик һәм драматург Шәриф Камалның әдәби һәм иҗтимагый эшенең 30 еллык юбилеен чын күңелдән котлыйлар һәм юбилярга сәламәтлек, иҗад энергиясе һәм татар совет әдәбиятын үстерү эшендә уңыш телиләр.

ӘРМӘНСТАН СОВЕТ ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ПРЕЗИДИУМЫ.

⁂

Украина Совет Язучылары Союзы Правлениесе Сезне, татар халкының күрнекле эшлеклесен һәм культура төзүчесен чын күңелдән котлый. Сезгә социалистик культура файдасына сәламәтлек, көч, энергия һәм иҗад уңышлары телибез.

УКРАИНА СОВЕТ ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ПРЕЗИДИУМЫ.

⁂

Сезнең иҗтимагый-әдәби эшегезнең 30 еллык юбилее көнендә Азербәйҗан язучылары Сезне—татар совет әдәбиятына нигез салучыны һәм татар культурасын үстерү эшендә гаять зур хезмәтләр күрсәткән кешене чын күңелдән котлыйлар. Сезгә озын гомер һәм социалистик Ватаныбыз файдасына нәтиҗәле эш телибез.

АЗЕРБӘЙҖАН СОВЕТ ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ПРЕЗИДИУМЫ.

⁂

Хөрмәтле Шәриф Камал, Сезне юбилей көнегез белән котлыйм. Озак еллар нәтиҗәле эш күрсәтүегезне телим.

Казагстан язучылары правлениесе члены *Гаишә Шәрипова.*

Язгы чәчү алдыннан

КЫРЛАРДА КАР СУЛАРЫН ТОТЫП КАЛУНЫ ЯХШЫ ОЕШТЫРЫЙК

Яз җитте. Кояш, җылы җил карны тиз эретә. Кар сулары урамнарда гына түгел, кырларда да җыела башлады. Хәзер колхозларның һәм совхозларның бурычы—кар суларын тотып калудан, игеннәр өчен күп итеп дым хәзерләүдән гыйбарәт. Әгәр дә кар суларын басуларда тотып калуны вактында оештырмасак, кыш буена тырышып, күп хезмәт куеп тоткан карлар иген уңышы өчен көткән нәтиҗәне биреп җиткермәячәк. Димәк, карны тоту гына җитми, аңардан хасил булган суларны да тотып калырга кирәк.

Шунлыктан, ВЛКСМ ның Татарстан Өлкә Комитеты бюросының 25 нче мартта кабул иткән карары аеруча зур әһәмияткә ия булып тора. Кар суларын басуларда тотып калу, ягни дым өчен көрәш, билгеле, комсомоллар эше генә түгел. Бу—барлык колхозчыларның һәм совхоз эшчеләренең эше. Шуның өчен дә ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросы үзенең 26 нчы март карары белән бу өлкәдә комсомол оешмасы күтәргән инициативаны яхшы дип табу белән бергә, Татнаркомземны, барлык район җир бүлекләрен, МТС һәм совхоз директорларын, райбашкармаларны һәм ВКП(б) райкомнарын һәрбер колхозда һәм совхозда кар суларын тоту эшен җәелдерергә мәҗбүр итте. Шик юк, бу чара алдынгы колхозлар тарафыннан гына түгел, бәлки барлык колхозлар тарафыннан да тормышка ашырылыр.

Быел кыш Татарстанда да кар катлавы җитәрлек калын булды. Күп кенә колхозлар кыш көне кар тоту оештырдылар. Ул иң әһәмиятле агротехника чараларының берсе иде. Хәзер исә бу тармакта инде икенче баскычка: кар тоту тәмам булганнан соң, кар суларын тотып калуга күчәргә кирәк.

Әнә шуны истә тотып Актаныш районының „Кызыл Көч" колхозында кар суларын тотып калуга хәзерлек эшенә күптән керештеләр. Иптәш Мурзина звеносы һәм Фарихә Нуриахметова бригадасы инде моннан 10—12 көн элек үк кар буалары өеп куйдылар.

Алдынгы колхозлар кар суларын тотып калу юлларын беләләр. Түңгә сөрелгән җирләрдә җыелган сулар чокырларга, зур елгаларга агып бетмәсен өчен, су агардай һәрбер урынны кар өемнәре белән чолгап алалар. Басуларның таусыман урыннарында да кар суларын шулай ук кар буалары ясау белән тотарга мөмкин. Мондый буаларны су ерып китмәсен өчен, аларны су сибеп катыру-бозландыру моңардан котылуга бик зур ярдәм итә.

Колхозлардагы стахановчылар кар суларын тотып калу эшендә яңа методларны да кулланалар. Кар катлавы тигез эресен һәм кар суы җиргә күбрәк һәм тигезрәк сеңсен өчен, кар өстеннән каток йөртеп, карны тыгызландыралар. Шуның белән бергә, кар күп өелгән урыннарда, мәсәлән, щитлар куелган җирләрдәге карларны тигез эретер өчен, аларны тарату эшен оештырырга кирәк.

Һәрбер колхозда кар суларын мөмкин кадәр күп итеп тоту өчен көрәшне бөтен киңлеге белән җәелдерергә кирәк. Ленин комсомолы бу эшнең башында барырга һәм барлык колхозчыларга үрнәк күрсәтергә тиеш.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ХӘЗЕРЛЕКНЕ ТИКШЕРҮ БУЕНЧА ЭШЧЕ-АВЫЛ ХӘБӘРЧЕЛӘРЕ РЕЙДЕН НИЧЕК ОЕШТЫРЫРГА

ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросының карары буенча 1 нче апрельдән 10 нчы апрельгә кадәр язгы чәчүгә хәзерлекне тикшерү буенча эшче-авыл хәбәрчеләренен рейде үткәрелә.

Бу рейдне ничек оештырырга?

Рейдне һәрбер районда район газетасы редакциясе оештыра. Барыннан да элек район газеталары янында колхозларның, МТС ларның һәм совхозларның рейд бригадалары җитәкчеләренең киңәшмәсен чакырырга кирәк. Партия райкомнары һәм район башкарма комитетлары бригадаларга җитәкчеләр сайлап алуда район газеталарына ярдәм итәргә тиешләр. Бу җитәкчеләр матбугат работникларыннан, эшче-авыл хәбәрчеләре активистларыннан, районның партия һәм совет активы арасыннан, авыл хуҗалыгы белгечләреннән сайлап алынырга тиеш.

Тикшерүне ничек оештырырга, рейднең нәтиҗәләрен матбугатта ничек яктыртырга кирәклекне шушы киңәшмәдә тулы итеп аңлатырга кирәк.

Колхозларның, МТС ларның һәм совхозларның рейд бригадалары составына эшче-авыл хәбәрчеләре, стена газеталарының редколлегия членнары, стахановчылар, җирле советларның депутатлары кертелергә тиеш. Һәрбер колхозда, МТС та, совхозда 3—5 кеше составында бер бригада төзелә, ә зур колхозда 2 бригада да булырга мөмкин.

Тикшерүне башлар алдыннан рейдтә катнашучыларга җентекләп инструктаж ясарга кирәк. Рейдтә катнашучы иптәшләр үзләре барачак тармакның хәлен тирәнтен өйрәнергә, кешеләр белән сөйләшеп, кимчелекләрнең сәбәбен ныклап ачарга, алдынгы тәҗрибәләрне табарга тиешләр.

Тикшерү нәтиҗәләре колхоз правлениеләренең утырышларында, колхозчыларның, совхоз һәм МТС эшчеләренең гомуми җыелышларында тикшерелергә тиеш. Болардан тыш, рейднең беткәнен көтеп тормыйча, чәчүгә хәзерлектә тикшерү барышында ачылган кимчелекләрне шунда ук төзәтүгә ирешергә кирәк. Районда эшче-авыл хәбәрчеләре рейденең йомгагын ачылган кимчелекләрне төзәтү буенча, эшче-авыл хәбәрчеләренең тәкъдимнәрен тормышка ашыру буенча тулы чаралар күрү өчен ВКП(б) райкомы утырышында әлбәттә тикшерергә кирәк.

Рейдне үткәрүне өлкә, район һәм стена газеталары битләрендә киң яктыртып барырга кирәк. Рейд көннәрендә МТС ларда, совхозларда һәм колхозларда стена газеталарын ешрак чыгаруны һәм махсус бюллетеннәр чыгаруны оештырырга кирәк. Макетлар чыгарып һәм башка юллар белән район газеталары бу эштә стена газеталарына ярдәм итәргә тиешләр.

Рейдтә иң әһәмиятлесе—нәтиҗәлелек өчен көрәш. Чәчүгә уңышлы хәзерләнүдә колхозчыларны, МТС һәм совхоз эшчеләрен туплауга, рейд барышында ачылган кимчелекләрне бетерүгә бары тик эшче-авыл хәбәрчеләре рейден үткәрүне уңышлы башкара алган газета гына ирешә алачак.

„Кызыл Татарстан" һәм „Красная Татария" газеталары редакцияләре эшче-авыл хәбәрчеләренең рейд бригадаларыннан тикшерү рейденең барышы турындагы материалларны өлкә газеталарына җибәрүләрен сорыйлар.

„Кызыл Татарстан",
„Красная Татария".

КАР СУЫ ТОТУ БАШЛАНДЫ

ШӨГЕР, 28 март. (Телефон буенча). Районның „Первое Мая" колхозы 25 гектар, „Байрак" колхозы 15 гектар, „Магнит" колхозы 24 гектар мәйданда кар суларын тотып калу чараларын үткәрде.

Районда быел ефремовчы иген уңышы алу турында йөкләмә алган 17 звено бар. Бу звенолар үзләренә беркетелгән барлык мәйданда кар суларын тотып калу чараларын күрәчәкләр. „Первое Мая" колхозында Маһянов һәм Угадарова звенолары бу эшне аеруча яхшы оештырганнар.

Колхоз басуларында кар суларын тотып калу мәсьәләсе буенча район үзәгендә актив киңәшмәсе үткәрелде. Киңәшмәдә ВКП(б) һәм ВЛКСМ Өлкә Комитетларының бу турыдагы карарлары тикшерелеп, аны тормышка ашыру буенча практик чаралар билгеләнде. Комсомолецлардан һәм район активыннан 22 кеше шушы эш буенча колхозларга киттеләр. Быел район колхозларында 2.900 гектар мәйданда кар сулары тотып калу чаралары үткәреләчәк.

Биккулов.

* * *

ТЕЛӘЧЕ, 28 март. (Телефон буенча). Колхоз басуларында кар суларын тотуны оештыру турында ВКП(б) һәм ВЛКСМ Өлкә Комитетларының карарларын үтәү буенча практик чаралар күреләэ. Бу турыда һәр колхозга аерым задание җиткерелде. Бу эштә колхозларга ярдәм итү өчен комсомол оешмаларына ярдәм итү өчен 22 кеше районнан җибәрелде.

„Чулпан № 2" колхозында кар суларын тотуга керешү аеруча яхшы оештырылган. Колхозның ефремовчы иген уңышы алугa ирешү турында йөкләмә алган иптәш Шәрифуллина звеносы 12 гектар мәйданда кар суларын тотып калу чарасын үткәрде инде.

* * *

КАЙБЫЧ, 28 март. (Телефон буенча). Кичә комсомолның район активы җыелышы булды. Җыелышта ВКП(б) һәм ВЛКСМ Өлкә Комитетларының колхоз басуларында кар суларын тотуны оештыру турындагы карарларын тормышка ашыру мәсьәләсе каралды. 22 кеше колхозларга җибәрелде.

„Активист" колхозының беренче бригадасында иптәш Тимершин звеносы бу эшкә беренче булып кереште һәм 5 гектар мәйданда кар сулары тоту чарасы үткәрде. Колхозның агротехнигы иптәш Әбсәгыйтов бу эшкә яхшы җитәкчелек итә.

Фирушин.

Бурят-Монголия республикасы, Селенгинский районының Сталин исемендәге колхоз председателе иптәш Родна Зориктуев бу колхозга Татарстан республикасыннан күчеп барган колхозчылар белән беседа ясый.

Бурят-Монголия киң, бай, матур край!

Татарстан республикасыннан Бурят-Монголия республикасына күчеп китүче хуҗалыкларның семья башлыклары февраль аенда үзләре күчеп барачак колхозларга киткәннәр иде. Шушы көннәрдә алар семьяларен алу өчен кайттылар. „Кызыл Татарстан" редакциясе бу иптәшләрнең кайберләрен беседага чакырып анда күргәннәре алган тәҗрибәләре белән уртаклашты. Без түбәндә Юдино районының „Авангард" колхозыннан күчеп китүчеләрнең беседаларын урнаштырабыз.

ПРОКОФИЙ КУЗНЕЦОВ

ШАТЛЫКЛЫ ОЧРАШУ

Без Улан-Удэ шәһәренә якынлашабыз. Шәһәр ерактан ук үзенә бер аерым матурлык белән балкып күренә. Ул күчеп килүчеләрне каршылау уңае белән матур итеп бизәлгән. Станциядә безне шәһәр хезмәт ияләре һәм шәһәр яңы районнарының колхозчылары каршы алдылар. Шунда ук зур митинг булды.

Шәһәрдә кунак булганнан соң безне Сульфатная станциясенә алып киттеләр. Аннан үзебез барачак колхоз 4 кенә километр икән. Анда безне каршы алу өчен колхоздан автомашиналар белән бик күп кеше килгән иде. Алар безне күтәреп алгандай каршыладылар. Әйберләребез кулга, аякларыбыз җиргә тими. Бик ачык, бик простой икән ул бурят халкы. Анда күрсәткән хөрмәтне сөйләп бетерерлек түгел. Шунда ук безне мунчада юындырдылар, ашарга-эчәргә җаның ни тели—һәммәсе әзер. Баруыбызга безнең өчен өйләр яхшы итеп хәзерләнеп куелган. Өйдә өстәл, урындык, умывальник, кровать шикелле кирәк-яракларга чаклы җиту. Радио кертелгән. Һәрбер семьягә дәүләт бәясе белән савым сыер, икешәр сарык, берәр кәҗә һәм дуңгыз бирделәр.

Шулай итеп барып кергән көнне үк үзебезне колхозның тулы хокуклы членнары итеп хис итә башладык. Тизрәк семьяләрне алып барып, яңа җирдә яңа көч белән эшләргә күңел ашкына.

СЕРГЕЙ ИВАНОВ

КУЛЬТУРАЛЫ, БАЙ КОЛХОЗ

Моннан киткәнче үк мин үзебез барачак колхоз турында, аның экономикасы турында ишетеп гаҗәпләнгән идем. Әйе, чынлап та гаҗәпләнерлек икән шул. Мин моны хәзер күреп беләм.

Сталин исемендәге колхозда 3 ферма бар. Анда 11 меңнән артык терлек исәпләнә. Терлекчелекне алга җибәрү өчен мөмкинлекләр гаять зур. Биредә 5 автомашина, двигатель бар. Колхозчылар культуралы таза тормышта яшиләр. Колхозның үзенең радио узелы, электростанциясе, бала тудыру йорты, амбулаториясе, 500 кеше сыешлы клубы, урта мәктәбе, ветпункты, җәмагать мунчасы, ашханәсе бар. Моңа өстәп, пар белән эшли торган тегермән, такта яру мастерское шикелле ярдәмче предприятиеләрне күрсәтергә кирәк. Һәрбер колхозчы йорты радио белән тәэмин ителгән. Улан-Удэ шәһәр театрыннан килгән 35 кешелек труппа колхозчыларга хезмәт күрсәтә.

ИШТ ДАНСОРУНОВ

(Бурят-Монголия АССР ның Сталин исемендәге колхоз председателе урынбасары)

ТИЗРӘК КИЛЕГЕЗ, ИПТӘШЛӘР!

Безнең колхозга Татарстаннан 18 хуҗалык күчеп килә. Без аларны шатланып каршы алабыз.

Бездә җир күп, терлекчелек алга киткән, тик эш көчләре генә җитешеп бетми. 29 мең гектардан артык җиребез бар.

Колхозчыларның тормышы көннән-көн яхшыра бара. Безнең колхоз членнарының һәрберсендә 2—3 еллык ашлык запасы бар. Сыерсыз бер генә хуҗалык та юк. Колхозның товарлыклы-сөтчелек фермасында мөгезле эре терлекләр саны 3.450 дән артык. Фермада сыер сауучы булып эшләүче стахановчыбыз Долцен Данзанованы СССР Верховный Советы орден белән бүләкләде.

Без үзебезгә килүче иптәшләрнең тизрәк килеп урнашуларын телибез. Тизрәк килегез, иптәшләр!

БОЛЬШЕВИКЛАР ПАРТИЯСЕНЕҢ IX НЧЫ СЪЕЗДЫ

(Съездның 20 еллыгына карата)

1920 нче елның 29 нчы мартында Москвада партиянең IX нчы съезды ачылды. Бу съездда партиянең 600 меңнән артык членыннан делегатлар катнашты.

Съезд чакырылу вактына героик Кызыл Армия, Ленин һәм Сталин җитәкчелеге нәтиҗәсендә, Англия—Франция империалистларының һәм аларның ак гвардеец ялчыларының 2 нче походын җимерде.

Кызыл Армия илебезгә тыныч тын алу өчен бер кадәр вакыт яулап алды. Бу тын алу вактын хуҗалык төзелеше өчен тулысынча файдаланырга кирәк иде. Партия җимереклеккә каршы көрәш оештыруга, җимерелгән хуҗалыкны аякка бастыруга керешТе. Транспортның җимереклеге илнең бөтен хуҗалык тормышына аеруча авыр йогынты ясады. Поездлар Москвадан Харьковка кадәр араны атналар буена үткәндә промышленностьне торгызу турында берниндн сүз булырга мөмкин түгел иде. Шунлыктан партия съездга кадәр үк инде берничә мең коммунистны транспортны торгызуга җибәрде.

Кызыл Армия сафларында 5 миллионлап кеше бар иде. Ләкин демобилизация игълан итәргә ярамый иде, чөнки әле сугыш куркынычы бетмәгән иде. Франция ипмериалистлары яшрен рәвештә Польша паннарын Советлар иленә каршы яңа сугышка хәзерлиләр иде. Кызыл Армиянең кайбер частьләре хезмәт армияләре хәленә күчерелделәр.

Тыныч тын алу вакты бик кыска булды. Шунлыктан аңардан тулысынча файдалану өчен күбрәк көч куярга кирәк иде. Партиянең верховный органы—РКП(б) ның IX нчы съезды игътибарны нак әнә шуңа туплады.

* * *

Үзәк Комитет докладында В. И. Ленин рус контрреволюциясенең баштан аяк коралланган гаскәрләрен һәм Англия—Франция интервентларын яш Советлар республикасының җиңүенә йомгаклар ясады.

Безнең җиңүләребезнең сәбәпләре Совет властеның дөрес политикасында,—халыкның интересларына туры килә торган һәм халык яклый торган политикада, Кызыл Армиянең халык белән аерылгысыз элемтәдә булуында, Кызыл Армиянең аңлылыгында, аның дисциплиналы һәм сугышка сәләтле булуында иде. Большевиклар бөтен илне фронт интересларына хезмәткә күтәрделәр һәм „Барсы да җиңү өчен!", „Барсы да сугыш өчен!"—дигән лозунгларны нык үткәрделәр. Большевиклар партиясе җиңүләрне оештыручы, Кызыл Армиянең тылына һәм фронтына җитәкчелек итүче үзәк булды.

Ленин халыкара пролетариатның бөек бердәмлеге турында, аның безнең илгә ярдәме һәм теләктәшлеге турында, Советлар республикасының „Архангельскига төшкән Англия солдатлары арасында, Севастопольгә төшкән Франция матрослары арасында, барлык илләрнең эшчеләре арасында үзенең тарафдарларын арттыруы" турында сөйләде. (Ленин, том XXV, бит 98).

Советлар республикасына каршы Антантаның беренче ике походы тулысынча җимерелү белән тәмам булды. Ленин безнең дошманнарыбызның лагерындагы каушау һәм таркау барлыкны күрсәтте, ләкин партияне үз-үзеннән тынычлануга һәм гамсезлеккә каршы кисәтте.

Съездда Владимир Ильич болай диде: „...Сугышны безгә һәр көнне көчләп тагулары мөмкин... Тынычлыкка таба булган адымнарыбызны без сугышка хәзерлегебезне көчәйтү белән бергә алып барырга һәм армиябезне һич сүзсез коралсызландырмаска тиешбез" (шунда ук, бит 102). Көчле һәм куәтле Кызыл Армия—әгәр империалистик державалар безгә һөҗүм итә калсалар, аларның тар-мар ителәчәкләренең реаль гарантиясе әнә шул.

Хуҗалык төзелешенең чираттагы бурычлары турындагы мәсьәлә съездда зур урын алды.

Шундый вакыт килеп җитте ки, игеннәрне җыеп алу, транспортка ремонт ясау, ягулык табу, бөтен хуҗалыкны аякка бастыру илнең тормышы өчен хәл иткеч булып әверелде.

Съездда В. И. Ленин: „... Бу эштә барлык илләрнең эшчеләре безгә карап, безнең яңа җиңүләребезне көтәләр!" диде. Транспортка меңнәрчә иң яхшы большевиклар тупланды. Съезд бөтен партия алдына транспортның хәлен тиз арада яхшырту бурычын куйды.

Шушы нигездә съезд промышленностьны торгызуның якындагы конкрет юлларын билгеләде.

Бердәм хуҗалык планы турындагы мәсьәләнең гаять зур әһәмияте булды һәм ул съездның игътибарын үзенә тартты. Илне электрлаштыру мәсьәләсе планда үзәк урынны алды.

1918 нче елның язында ук инде Ленин электрлаштыру идеясен күтәрде һәм соңыннан бу мәсьәләгә күп тапкырлар кагылды. 1920 нче елның февралендә аның инициативасы белән Россияне электрлаштрыу буенча дәүләт комиссиясе (ГОЭЛРО) төзелде. Бу комиссия шул ук елны электрлаштыру планын эшләп чыгарды. Бу план инде хәзер күп тапкыр арттырып үтәлде.

Лениннең электрлаштыру планын бик нык яклап иптәш Сталин болай дип язды:

„Чыннан да бердәм һәм чыннан да, кавычкасыз, дәүләтчә хуҗалык планының оста итеп эшләнгән беренче язмасы. Хуҗалык ягыннан артта калган Россиянең Совет өскормасына безнең заманда Маркcча чыннан да реаль һәм хәзерге шартларда бердәнбер мөмкин булган техник-производство базасы салырга тырышу".

Троцкий һәм Рыков электрлаштыруга каршы зарарлы һәм реакцион планнар корып, Лениннең электрлаштыру идеясенә каршы чыктылар.

Ленин һәм Сталин җитәкчелегендә партия съезды илне электрлаштыруның Ленин планын кабул итте.

Съездда профессиональ союзлар турындагы мәсьәлә хуҗалык бурычлары белән нык бәйләнештә булып килеп басты. Иптәш Сталинның турыдан-туры катнашы белән язылган резолюциядә хуҗалык төзелешендә профессиональ союзларның актив катнашулары кирәклеге аеруча күрсәтелде. Резолюция профсоюзларның ролен билгеләп, аларның „коммунизм мәктәбе" икәнлеген күрсәтте һәм алар алдына сугыш вактындагы кебек эшләргә, предприятиеләрне идарә итүдә ялгыз җаваплылыкка күчү кирәклеген эшчеләр сыйнфының киң катлау массасына аңлатырга, эшчеләрдән хуҗалык җитәкчеләре хәзерләп үстерергә, дигән конкрет бурычларны куйды.

Съездда принципсыз демагогик оппортунистлар группасы Ленин—Сталин юлына каршы чыкты. Бу группа үзен „демократик централизм" группасы дип атады. Бу, партиягә һәм Совет властена каршы дошман булган бер төркем бюрократлар группасы иде һәм ул үзенең карашлар дип аталган вак буржуаз чүп-чарын партиягә һәм аның Ленинче—Сталинчы Үзәк Комитетына каршы куярга маташты. Туарылган һәм кабахәт демагогияләре өчен Ленин аларны „барлык кычкыручылардан да катырак кычкыручы" фракция дип атады.

Башында Сапронов, Осинский, В. Смирнов торган „демократик централизм" группасы партиядә тимердәй дисциплина булдыру турында Ленин принципына каршы, Совет дәүләтендә партиянең җитәкче роленә каршы, партиянең үзәкләштерелгән җитәкчелеге булган Үзәк Комитетка каршы чыкты. Бу кабахәтләр үзләренең партиягә каршы булган һөҗүмнәрен Совет власте политикасына каршы да күчерделәр. Баштан аяк вак буржуаз анархизм белән сугарылган бу группа совет аппаратын үзәкләштерүгә каршы, хезмәт дисциплинасына каршы, промышленностьта директорларның ялгыз җаваплылыкларына каршы кискен төстә туплaндылар.

Партиягә каршы группаның лидерлары Сапронов, Осинский, В. Смирнов РКП(б) ның IX нчы съездында партия Үзәк Комитетына каршы кискен һөҗүм белән чыктылар, ике йөзле Рыков һәм Томский аларны якладылар.

Партиягә каршы барлык чыгышларга һәм пролетариат диктатурасын йомшатырга, какшатырга маташуларга съезд ныклы удар ясады. Партиянең IX нчы съезды карарлары партиянең эчке дисциплинасын тагын да ныгытуга ярдәм иттеләр, партиянең Ленинче—Сталинчы төп юлын тайпылышсыз үткәрүне тәэмин иттеләр.

* * *

Партиянең тарихи IX нчы съезды булганга 20 ел үтте. Бу съезд гражданнар сугышының гаять авыр шартларында, вакытлы һәм кыска тын алу моментында илебездә социализм төзү буенча бөек эшләрнең гаять зур программасын билгеләде. Электрлаштыруның дәүләт планы—„10—20 елга бөек программа" илебездә социализм җиңүенең юлларын билгеләде.

Бурыч социалистик җәмгыять хуҗалыгы төзүдән, өр яңа индустрия һәм машиналаштырылган эре авыл хуҗалыгы булдырудан гыйбарәт иде.

IX нчы съездда ясаган докладының азагында Ленин болай диде: „Әгәр без бу бурычны хәл итсәк, без кансыз фронтта гражданнар сугышы фронтында җиңгәнгә караганда ким булмаган җиңүгә ирешәчәкбез".

Лениннең даһиларча алдан күрүе тормышка ашырылды.

Советлар Союзы куәтле социалистик держава булып, алдынгы индустрия һәм дөньяда иң эре, машиналаштырылган авыл хуҗалыгы иле булып, чәчәк атучы социалистик культура иле булып әверелде.

Бөтен дөнья күләмендә тарихи әһәмияте булган һәм Сталин Конституциясендә закон тәртибендә ныгытылган җиңүләр социализмның барлык дошманнарына каршы килешмәүчән көрәштә, Лениннең эшен бөек дәвам иттерүче иптәш Сталин җитәкчелегендә партия һәм бөтен совет халкы тарафыннан һәр вакыт алып барылган һәм алып барыла торган көрәштә ирешелделәр.

М. Шилов.

АТАКЛЫ СОВЕТ ЯЗУЧЫСЫ ШӘРИФ КАМАЛГА ЯЛКЫНЛЫ СӘЛАМ!

ОЗАК ЯШӘ

(Бүләк тапшыру җыры)

Чын күңелдән котлап утыз еллык
Намуслы эш—иҗад бәйрәмен,
Сиңа бүләк итәм, Шәриф абзый,
Чәчәк аткан гөлләр бәйләмен.

Язгы чәчәкләрнең иң матурын
Күпме генә сайлап йөрсәм дә,
Яхшы аңлыйм: якты талантына
Тиң түгелләр алар бирсе дә.

Бу гөл фәкат керсез дуслыгымның
Җиткерүче булыр сәламен.
Озак еллар эшчән кулларыңда
Армый язсын үткен каләмең.

Совет иле халкын куандырып,
Дошманнарның эчен яндырып,
Озак яшә!—
Һәрбер сүзең белән
Мәңге сүнмәс эзләр калдырып.

Озак яшә!—
Бөек Сталинның
Төп законы биргән бәхетне
Романнарда, сәхнә әсәрендә
Чагылдырып. Безнең вакытның
Безнең гүзәл чорның геройларын,
Орден алган батыр улларын,
Орден алган данлы кызларын
Һәм аларның якты уйларын,
Шатлык белән тулы тойгыларын
Иҗадыңда җырлап яшә син!
Яшәсен ил—сине тудырган!
Һәм үстергән халык яшәсен!

Кави Нәҗми.

Совет патриотлары образын көтәбез

Коммунист язучы Шәриф Камал хәзерге көндә, ВКП(б) ның XVIII нче съезды тарафыннан куелган төп политик бурычтан чыгып, илебезнең хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләү мәсьәләсе буенча үзенең иҗад эшен зур осталык белән дәвам иттерә. Ул „Таң атканда" романының икенче кисәген тәгәлләп килә. Монысында, капитализм калдыкларына, иске гореф-гадәтләргә каршы көрәшне чагылдырган яңа образлар бирелячәк. Аннары, Донбасс эшчеләре тормышыннан „Сафура" дигән пьеса өстендә эшли. Бу әсәрдә автор стахановчылык хәрәкәте тудырган хезмәт батырларын күрсәтүне күздә тота.

Шәриф Камалның 30 еллык әдәби һәм җәмагат эше өлкәсендәге хезмәтен билгеләп үткәндә, совет җәмагатчелеге талантлы язучы алдына яңа таләпләр куя. Һәм ул шулай булырга тиеш тә. Шик юк, Шәриф Камал социалистик Ватанның ялкынлы патриоты буларак, партиябезнең XVIII нче тарихи съезды куйган бурычларны үтәү буенча совет әдәбиятында һәм драматургиясендә яңа образлар бирер, яңа үрнәкләр күрсәтер.

У. Әхмәтов.

Шәриф Камал татар совет язучылары арасында.

БЕЗНЕҢ ТЕЛӘКЛӘР

Миңа, артист булып Татар Дәүләт Академия театрына килеп керү белән, Шәриф Камал аганың драма әсәрләрендәге төрле типлар өстендә эшләргә туры килде. „Хаҗи әфәнде өйләнә" дә артист Җәләл ролен, „Ут" та журналист Гомәр, „Козгыннар оясында" әсәрендә Садри һәм Мәхмүт, „Томан арты"нда Габбас, „Таулар" да Зариф, „Матур туганда" әсәрендә Нагим ролен һәм башка бик күп рольләрне башкардым. Шәриф Камал аганың әсәрләре һәм аның тарафыннан тудырылган образлар минем иҗад үсешемдә бик күп ярдәм иттеләр.

Без киләчәктә Шәриф Камал агадан бүгенге көннең җанлы кешеләрен—кыенлыклардан курыкмаучы, үз Ватанын яратучы, үз халкы өчен нинди генә батырлыклар эшләргә дә хәзер торучы кешеләр—илебезнең геройлары образын бирүен телибез.

Х. Сәлимҗанов.

Татарстанның атказанган артисты.

***

Без, театр өлкәсендә эшләүче яшьләр, Шәриф Камал аганың әсәрләре аша тормышны өйрәнәбез. Аның әсәрләрен яратып укыйбыз һәм әсәрләрендә бирелгән типларны яратып уйныйбыз. Шуның белән бергә, Шәриф Камал агадан киләчәктә дә совет чынбарлыгын бөтен тулылыгы һәм матурлыгы белән гәүдәләндергән әсәрләр бирүен телибез. Ул әсәрләрдә хезмәткә, укуга, социалистик Ватанга, семья тормышына һәм балага чын мәхәббәт белән караучы батыр совет хатын-кызлары образларын күрәсебез һәм шуларны сәхнәдә гәүдәләндерәсебез килә.

Яшь артисткалар: *Җиһаншина, Г. Ибраһимова, М. Миңлебаева, М. Шарипова, З. Басыйрова, Т. Тамендарова.*

ЧОРДАШЫМА

Мин язучы Шәриф Камал белән беренче тапкыр 1912 нче елларда Оренбургта (хәзерге Чкалов шәһәре) концертлар биреп йөргән чакта очраштым. Шәриф Камал журналист буларак та, музыканы гаять дәрәҗәдә ярата торган кеше буларак та, минем концертларым белән бик нык кызыксынды.

Язучы белән икенче тапкыр очрашу Бөек Октябрь Социалистик революциясеннән соң, мин Казанга күчеп эшли башлаганнан соң булды. Бу вакытта инде ул яхшы ук танылган язучы иде. Без аның белән баштан үткәннәр турында озаклап киңәеп сөйләшеп утырдык. Аннан соңгы елларда мин аның белән якын дуслар-ча еш кына очраша идем. Ә 1930 нчы елны республикабызның 10 еллык юбилее көннәрендә без икәү бергә Бондюг заводына бардык. Безнең сәнгат бригадасы Бондюг заводы эшчеләре һәм районның колхозчылары өчен концертлар бирде. Шәриф Камал исә үзенең эшчеләр тормышыннан алып язачак романы өчен материаллар туплап йөрде.

Якын дустым Шәриф!

Синең 30 еллык данлыклы иҗад бәйрәмең барлык совет җәмагатчелегенең шатлыклы бәйрәме ул. Сиңа озын гомер телим. Синең бәйрәмеңдә үземнең якын дусларым—көмеш телле гармоннарым белән катнаша алуыма чын күңелемнән шатланам.

Иҗад эшеңдә тагын да мулрак уңышларга ирешүеңне теләп калам.

Фәйзулла Туишев.

ТАССР ның атказанган артисты.

ИСТӘ КАЛГАННАРДАН

Минем, Оренбургта (хәзерге Чкалов) „Хөсәения" мәдрәсәсендә укып йөргән яшь үсмер вакытлар. Әдәбият белән бик кызыксынабыз. Әдәби китаплар гына түгел, аерым газета, журналларда басылган әдәби парчалар да безнең күздән үтми калмыйлар. Ул вакытларда татар әдәбиятында азмы-күпме үзенең каләме белән танылган язучыларны без биш бармагыбыз шикелле беләбез. Шәриф Камал белән дә „Вакыт" газетасында һәм „Шура" журналында басылгалап килгән аерым хикәяләре аша гына булса да таныш идек.

1914 нче елны Ш. Камалның „Хикәяләр төркеме" дигән зур гына җыентыгы басылып чыкты. Иптәшләр белән без аны бик зур кызыксыну белән укып чыктык, кайбер урыннарын икешәр-өчәр кат укып чыга һәм фикерләр алыша идек.

Беренче тапкыр мин Шәриф Камалны 1925 нче елның ахрында „Кызыл Татарстан" редакциясендә күреп таныштым. Безнең тагын да якынрак танышу 1929 нчы елның җәендә язучылар экскурсиясе (Казан—Астрахань) вактында булды.

Шәриф абзый ул болай карaганда аз сүзле кеше кебек күренсә дә, эштән буш вакытларында уен - көлке сөйләргә, шаярырга да бик ярата. Шуның белән бергә аның сүзләреннән тирән белемлелек аңкып тора. Ул, Көнчыгыш әдәбияты, шулай ук, иске һәм яңа рус әдәбияты белән бик яхшы таныш булу өстенә, Көнбатыш Европа әдәбиятын да күп укыган. Ләкин ул үзе турында күп сөйләргә яратмый. Кешеләргә бик яхшы һәм матур киңәшләр бирә. Бигрәк тә әдәбият мәсьәләләрендә аның биргән төпле һәм акыллы киңәшләрен күп тапкырлар ишетергә туры килгәне бар.

М. Гали.

БЕЗНЕҢ ТЕЛӘКЛӘР

Чорыбызның танылган язучысы Шәриф Камал аганың әсәрләрен мин тирән кызыксыну белән яратып укыйм. Аның әсәрләре һәм ул әсәрләрдә бирелгән образлар йөрәкне дулкынландыралар, җанга рәхәт бирәләр һәм чынбарлыкны танырга өйрәтәләр. Шуның өчен мин, Шәриф Камал аганың кайбер әсәрләрен, аерым алганда, „Таң атканда" һәм „Матур туганда" дигән романнарын 2—3 тапкыр укып чыктым. Аларны укыган саен яңа матурлык һәм ям табам.

Мин Шәриф Камал агадан тагын да зуррак әсәрләр бирүен көтәм. Ул әсәрләрдә илебезнең патриотлары образларын күрәсем килә һәм безнең сөекле язучыбыз боларны эшләр дип чын күңелемнән ышанам.

И. Фәйзуллин.

3 нче фанер заводы эшчесе.

***

Шәриф Камал аганың тирән эчтәлекле әсәрләре яңалыкны хис итүгә, тормышны дөрес күрә белүгә, иҗтимагый процесларны аңларга өйрәтәләр. Ул әсәрләр укучыларның хисләрен иркәлиләр, тойгыларын оештыралар, дошманга карата нәфрәт тудыралар.

Без Шәриф Камал аганың әсәрләрен яратып укыйбыз. Безгә, бигрәк тә, „Матур туганда" романы ошый. Андагы Мәдинә, Каюм, Әхмәт образлары безне сокландыралар.

Шуның белән бергә, без киләчәктә дә, Шәриф Камал ага, Сездән гүзәл әсәрләр көтәбез. Ул әсәрләрегездә Сталин эпохасында туган совет геройлары, герой хатын-кызлар образларын гәүдәләндерүегезне сорыйбыз.

Әхмәдиева, Шакирова, Валитова, Хайбуллина һ. б.

Казан Педагогия институты студентлары.

КУНАКЛАР

Шәриф Камалның 30 еллык юбилей тантанасында катнашу өчен Казанга күп кенә шәһәрләрдән кунаклар килә. Алар арасында СССР Совет Язучылары Союзы правлениесеннән Әхмәт Фәйзи, Панченко Миних, Удмуртия Совет Язучылары Союзы правлениесеннән шагыйрь Чайников, Чувашстан Совет Язучылары Союзы правлениесеннән Васянка, Мордовия Совет Язучылары Союзы правлениесеннән Вечканов һәм башка иптәшләр бар.

Хәбәрчегез белән булган беседада Удмуртиядән килгән шагыйрь Чайников түбәндәгеләрне белдерде:

— Безнең республикабызда татарның күренекле язучысы Шәриф Камал юбилеена хәзерлек эшләре февраль аенда ук башланды. Удмуртия Совет Язучылары Союзы правлениесе янында 5 кешелек юбилей комитеты (председателе республика күләмендә чыга торган „Ленин юлы" газетасының җаваплы редакторы иптәш Әхмәтҗанов) оештырылды. Комитет махсус төзелгән план буенча зур гына эш башкарды. Юкаменски, Бализино, Можга һәм башка районнарда, шулай ук татар мәктәпләрендә Шәриф Камалның тормышы һәм иҗады турында беседа, докладлар үткәрелде. Удмуртия шагыйрьләре һәм язучылары Шәриф Камалның күп кенә әсәрләрен тәрҗемә иттеләр. Мин үзем „Эш эзләгәндә", „Күптәннән бирле" һәм башка новеллаларны тәрҗемә иттем.

Республика газетасы „Ленин юлы"нда Шәриф Камалга багышланган 5 сәхифә бирелде. Шулай ук „Удмурдская правда", „Удмурдская коммуна", „Молодой большевик" газеталарында һәм „Молот" журналында да күп кенә материаллар басылды.

Удмуртиянең Радиокомитеты, удмурд, рус һәм татар телләрендә Шәриф Камал турында тәртипле рәвештә тапшырулар оештырды.

Ижевскийдагы татар клубында Шәриф Камалның „Матур туганда" дигән пьесасы бара. Пьесаны клубның татар театры куя. Шунда ук Шәриф Камалга багышланган күргәзмә төзелде. Үзлегеннән эшләүче художниклар юбилярның портретын ясадылар.

Юбилей көнне 20 нче номерлы татар урта мәктәбендә, Удмуртиянең Совет Язучылары Союзы правлениесендә һәм башка учреждениеләрдә Шәриф Камалга багышланган кичәләр үткәрелә.

Р. Н.

Йөрәк инженеры

Синең уйлар якты йолдыз кебек
Нур чәчтеләр кара төннәрдә.
Хаклык сүзен авыр еллар аша
Алып килдең безнең көннәргә.

Томаннар һәм биек таулар кисеп,
Утлар кичеп юллар үттең син
Һәм туздырып козгын ояларын
Бетмәс байлык иҗад иттең син.

Илебездә якты таңнар атты,
Көннәр матур булып тудылар,
Сулган гөлләр, Ленин кояшыннан
Нурлар алып шиңмәс булдылар.

Син күрәлдең үзең хыял иткән
Сагынып көткән таңнар атканын.
Син күрәлдең сөйгән Ватаныңда
Җәүһәрләрнең җирдә ятмавын.

Бәхтең тапкан, чәчәк аткан илдә
Йөрәк җылыбызга төренеп,
Озак яшә, сине кеше иткән
Халыкларны сөеп, сөелеп!

С. Урайский.

ОБРАЗЛАР МАСТЕРЫ

Шәриф Камал Столыпин реакциясе елларында әдәбиятка килеп, изелгән халыкларны яклап тавыш бирде. Ул, эшчеләр тематикасы белән, җәберләнгән кешеләрне гәүдәләндерүе белән аерылып торды. Аның новеллаларының күбесе эшчеләрне, сезонникларны, гомумән хезмәт ияләрен, аларның тормыш, көнкүрешләрен җанландыруга багышландылар. Ул үзенең әсәрләре белән чынбарлыкка кыю карап, капиталистик җәмгыять һәм эксплуатация астында, Столыпин реакциясе басымы астында газап чиккән хезмәт ияләре катлавының иң яхшы сыйфатларын күрсәтте. Бу—татар әдәбиятында гаять кыю һәм прогрессив күренеш иде. Ул шул вакытта кризис кичергән демократик әдәбиятта аеруча сизелерлек булды. Чөнки реакция елларында Г. Тукай, Г. Камал, М. Гафури кебек намуслы язучылардан башка, „...революциянең попутчиклары арасында таркаулык" (ВКП(б) тарихының кыскача курсы) башланган иде инде. Шәриф Камал шул вакытта үзенең тавышын, реакциянең караңгылыгында яңгырап торган Тукайлар авазына кушты.

Шәриф Камал, әсәрләренең саф һәм оригинал булуы белән кешенең игтибарын үзенә тарта иде. Ш. Камал, формасы белән дә, эчтәлеге белән дә, оригинал әсәрләр язды. Бу әсәрләр белән бергә татар әдәбиятында яңа жанр җәелде, хезмәт ияләренең яңа образлары килеп чыкты. Шәриф Камал ул образларны чын күңелдән, кайнар мәхәббәт белән гәүдәләндерде.

Кеше Ш. Камал әсәрләрендә почетлы урын ала. Язучыны аерым вакыйгаләрдән бигрәк, шул вакыйгаләрне тудыручы образлар—характерлар кызыксындыра. Бу нәрсә—Ш. Камалның әдәби стилен билгели.

Ул һичбер нәрсә белән аерылмый торган гади көн, гади тормыш алды һәм шул реаль обстановкада кешенең характерын сурәтләде. Тормышка нигезләнеп, тормыш шартларыннан чыгып бирелгән мондый психологик төс кеше рухының бөекләген күрсәтүгә ярдәм итте. Шәриф Камал Максим Горькийның иң яхшы шәкертләреннән берсе булды, хезмәт ияләренең иҗад итү көчләрен күрде.

1909 нчы елда язылган „Уяну" исемле беренче әсәреннән үк Ш. Камал югарыда әйтелгән юл белән бара. „Уяну" новелласы эшче Мусаның катлаулы психологик образын бирә. Муса кешелекле характерга ия. Аңарда яхшы хисләр, күркәм сыйфатлар тулып ята. Муса киң холыклы, матур табигатьле кеше. Ләкин капитализм тормышы Мусаның шул яхшы холыкларын агулый, аның рухын төшерә, нечкә хисләрен, якты акылын тупасландыра. Шул капиталистик тормыш аны һәм хатынын тәмам үтерә.

„Козгыннар оясында" хикәясендә дә авыр эксплуатация һәм караңгы тормыш астында изелә торган шахтерлар образы гәүдәләнә. Революциягә чаклы яшәгән шахтерлар тормышы тупас бер төрлелек белән, тончыктыргыч һавасы белән күренә. Шахтерлар дөньяның барлык матурлыкларыннан мәхрум яшиләр.

Бөтен җирдә халык газап чигә. Капиталистик тормыш аларны бер урыннан икенче урынга куа; тик алар хәерчелектән, бәхетсезлектән котыла алмыйлар. Бәхет кайдадыр алардан читтә йөри. Ләкин бер характерлы як бар. Бу халыклар өметсез түгел. Алар, бу урында булмаса, икенче җирдән бәхет табарга ышаныч саклыйлар. Шул өмет аларны йөртә, күңелләрен күтәрә. „Бәхет эзләгәндә", „Чит илдә", „Ата" новеллалары, „Акчарлаклар" повесты шундый эшчеләрне күрсәтә. „Ата" новелласында, ашлык амбарларында эшләүче сезонлы эшче Корбангали әле яңа туган улының аны авыр эштән коткарасына ышана.

Ләкин шуны әйтергә кирәк, аның бу хезмәт ияләре бәхеткә ирешә алмыйлар, тук тормыш күрмиләр һәм сыйнфи көрәшкә дә кереп китмиләр. „Акчарлаклар" повестында шторм вактында, балыкчылар берләшеп, көрәшкә чыгу турында әйтүгә чаклы килеп җитәләр, ләкин бу, бердән, көчсез, икенчедән, стихия төсендә килеп чыккан бер фикер була. Аларның хуҗаларга юнәлгән ачулары ныклы бер эзгә салынып, оешкан төс алмый. Шәриф Камал авыр эксплуатацияне, рәхимсез тормышны гәүдәләндерә, ләкин революцион нәтиҗә ясалмый, сыйнфи көрәш аша социаль революция булдыру кирәклеген әле белми. Шуңа күрә капиталистик тормыштан ризасызлану тойгылары ныклы бер юлга салынмаган төстә бирелә.

Шәриф Камал, кол булып яшәгән хезмәт иясе хатын-кызлар образын да гәүдәләндерде. Ул хатын-кызларга хөрмәт белән карарга чакырды, хатын-кызлардан нечкә тойгыларны, җанга җылылык бирә торган шигыри хисләрне, ана мәхәббәте кебек ягымлы, саф һәм күркәм мәхәббәтләрне күрде. Хатын-кызларны мәсхәрәләүчеләрне фаш итеп, гаепләп чыкты. „Сулган гөл", „Тормыш көе", „Эч пошулы", Нәфисә" һәм башка шуның кебек новиллалар моны ачык күрсәтәләр.

Бөек Октябрь Социалистик революциягә чаклы капитализмның бозык якларын фаш итеп, критик-реализм нигезендә әсәрләр язган Ш. Камал, революциядән соң бик нык үсте. Идея-политик яктан чыныгу өстенә, художество әсәрләренең катлаулы жанрларын, югары үрнәкләрен бирде. Аның әсәрләре инде һәм эчтәлек, һәм форма ягыннан революциягә чаклы иҗадыннан бик нык аерылып тордылар. Ул, революциягә чаклы көрәш юлын тапмаган, сыйнфи көрәшкә чаклы күтәрелмәгән хезмәт ияләрен күрсәтсә, революциядән соң җиңүче пролетариатны, аларның социализм идеяләре өчен көрәшүләрен гәүдәләндерде. Революциягә чаклы Ш. Камал иҗады өчен кече формалар—новелла—хикәяләр характерлы булса, революциядән соң аның өчен катлаулы жанрлар—роман, драмалар характерлы.

Ш. Камал большевик язучы буларак, совет чынбарлыгында туып килгән яңалыкларны үз вактында күрә белде, яңа образларны, яңа характерларны, яшьләрдә урнашып килә торган яңа мөнасәбәтләрне, коммунистик моральне гәүдәләндерде.

Ул чынбарлыкны тар рамкаларда күрсәтмәде, аның геройлары бикләнеп яшәмәделәр. Ул геройлар бай һәм катлаулы характер белән сурәтләнделәр: алар җанлы булдылар, көрәштеләр, сөйделәр, газап чиктеләр, бәхеткә, ирекке омтылдылар, ләкин шәхси омтылышларын халык интересыннан аермадылар.

Шәриф Камал 1926 нчы елда „Таң атканда" исемле романын язып бетерде. Ул беренче тапкыр 1927 нче елда басылып та чыкты.

„Таң атканда" романы татар әдәбиятында революциядән соң язылган романнарның беренче уңышлы үрнәге. Бу әсәрдә большевиклар образыннан Мохтар Булатов типы аеруча тулы һәм яхшы эшләнгән. Ул укучыларның күз алдында, революция белән бергә эзлекле рәвештә үсеп бара, аның батыр тормышы, эчке дөньясы гәүдәләнә.

Булатов Ташкент тимер юлының баш мастерскоенда эшли һәм халык арасында революцион агитация алып бара. Ул пролетариатның җиңеп чыгуына ышана һәм властьның эшче - крестьян депутатлары советына күчәргә тиешлеген әйтә.

Язучы бу типны гади бер көрәшче төсендә гәүдәләндергән. Ул большевиклар партиясенең рядовой члены. Аның көче, энергиясе бар һәм ул бу көчне массаның симпатиясен яулап алуга куя, хезмәт ияләренең фикрен вакытлы хөкүмәткә каршы туплау юлыннан бара. Властьны Советлар кулына алуның авырлыгын һәм „бары корал көче белән чишелергә мөмкин" икәнен аңлый. Шуны әйтергә кирәк, Булатов лаклаган, шомартып буялган ясалма кеше түгел. Автор аны большевик итү өчен генә кызартырга тырышмаган. Булатов 1917 нче елгы рядовой революционерлардан типик образ буларак бирелгән. Шуңа күрә аңарда шул чор өчен характерлы җитешкән, җитешмәгән гадәтләр бар. Ул реаль тип, революцион вакыйгаләр эчендә үсә торган, көрәштә чыныга торган кеше.

Романда татар буржуазиясенең, милләтчеләрнең шул чор өчен типик булган образлары бирелгән.

Менә „яңа" купец типы—Сафин. Ул империалистик сугыш вактында баи. „Социализм ул концентрация капиталы аркасында гына булырга мөмкин" дигән сүзләре аның империалистик карашлы кеше икәнен ачык күрсәтәләр.

***

Шәриф Камал 30 еллык әдәби хезмәт чорында зур һәм катлаулы юл узды. Бу вакыт эчендә ул бик күп классик әсәрләр тудырды һәм шулар аша халыкның хисләрен тәрбияләп, аларны якты, бәхетле тормышка чакырды.

Совет власте елларында Ш. Камал зур совет язучысы булу дәрәҗәсенә үсте һәм социализм төзүдә, хезмәт ияләренә коммунистик тәрбия бирүдә әсәрләре белән актив катнашты. Аның әсәрләре югары художестволы булдылар, интернационализм рухында язылдылар, пролетар революция, коммунизм идеяләре белән сугарылган булдылар.

Гази Кашшаф.

Инструментлар цехы алда бара

Язу машиналары заводының алдынгы стахановчылары Татарстанның XX еллыгын лаеклы каршылау өчен өсләренә алган йөкләмәләрне намус белән үтиләр.

Кызыл байраклы инструменталь цех коллективы аеруча яхшы эшли. Цех 1940 нчы елның беренче көннәреннән бирле планны системалы рәвештә арттырып үти. Бу цехның алдынгы стахановчылары Рыбин, Ипатов, Неделько, Черепных, Камалеева иптәшләр яңа нормаларны 180—390 процент итеп үтиләр. Токарьлардан Щелоков, Шаһиәхмәтов, Гәрәфеев иптәшләр соңгы айларда бик яхшы эш үрнәкләре күрсәтә башладылар. Иптәш Щелоков февраль ае планын 411 процент итеп үтәп, продукцияне 100 процентлы белән отлично билгесенә эшләп чыгарды.

Строгаль иптәш Ибраһимов ике строгаль станогында эшләп, февраль аенда планны 450 процент итеп үтәде һәм 823 сум хезмәт хакы алды.

Калильщик Дыдыин һәм Жандаров иптәшләр беренче төрле профессияне үзләштерү өстендә эшлиләр. Алар ялкынлы печьләрдә эшләү булганда ирдә кургашын ванналарында эшләүне үзләштерәләр.

Механика цехы слесарьлары Гыйззәтуллин, Ильин, Анисимов, Степанов, Ишнятуллин, Халитов, Закирова иптәшләр хәзер көнлек нормаларны ике-өч тапкыр арттырып үти башладылар. *Г. Кушаев.*

БЕР РАЙОННЫҢ БЮДЖЕТЫ

Әзнакай районы бюджеты соңгы 5 ел эчендә 310 процентка үсте. Шул исәптән мәгариф эшләренә тотыла торган расходлар сумасы 390 процентка, сәламәтлек саклау чараларына тотыла торган расходлар сумасы 359 процентка үсте.

1939 нчы елда гына да культура чараларына 1 миллион 860 мең сум акча тотылды. Район бюджеты карамагында бер больница, 3 амбулатория, 3 фельдшер-акушерлык пункты, 2 урында бала тудыру йорты, балалар консультациясе бар.

Узган ел районда урта, тулы булмаган урта һәм башлангыч мәктәпләрдә барлыгы 5.891 бала укыды.

Ләкин Әзнакай районында бюджетны үтү буенча кимчелекләр дә бар әле. Бюджет белән эш итүче кайбер оешмаларның җитәкчеләре тарафыннан җаваплысыз караулар булу нәтиҗәсендә, артык расходлар тоту, яки билгеләнгән акчаны тотмый калдыру фактлары булды. Узган ел исәпләргә тотылырга тиеш булган 7 мең сум акча файдаланылмады. Мәлбагыш, Түбән Яки, Балтач һәм башка күп кенә авыл советлары председательләренең бюджет үтәлеше өстеннән тиешле контрольне булдырмаулары аркасында, авыл бюджетлары буенча 30 мең сумнан артыграк акча тиешле урнына файдаланылмый калды.

Д. Зиннуров.

13 нче мәктәпнең әдәбият түгәрәге членнарыннан (сулдан уңга) М. Әүхәдиев, И. Галиев һәм С. Кимов иптәшләр Шәриф Камалның квартирасында.

И. Галиев фотосы.

Ш. Камал юбилеенә багышланган кичәләр

Шушы көннәрдә Казан Дәүләт Педагогия институтының актовый залында әдип Шәриф Камал белән очрашу кичәсе булды. Кичәдә язучының тормышы һәм иҗады турында институтның әдәбият укытучысы иптәш Вәзиевның докладын тыңладылар.

Доклардан соң Татар Дәүләт Опера театры һәм Радиокомитет артистлары катнашы белән зур концерт бирелде. Кичәдә гармонычы Фәйзулла Туишевның, шулай ук язучылардан Әхмәт Фәйзи, Хәсән Туфан һәм башка иптәшләрнең чыгышлары булды.

Залда матур гына күргәзмә оештырылган иде.

Студентларның әдәбият түгәрәге үзенең „Әдәби альманах“ дигән журналының Ш. Камалга багышланган 3 нче номерын чыгарды.

* * *

80 нче номерлы урта мәктәп (Сталин районы) укучылары һәм укытучылары үзләренең сөеп, яратып укый торган язучылары Шәриф Камал белән очраштылар. Шәриф Камал ага залга килеп керү белән аның хөрмәтенә алкышлар яңгырады. Казан Дәүләт Педагогия институтының фәнни работнигы иптәш Фәйзуллина докладыннан соң, укучылар һәм укытучылар юбилярны котладылар.

Ш. Камал ага үзенең чыгышында, котлаучыларга рәхмәт белдерде һәм мәктәп укучыларына кадәр булган укуның авыр шартлары, үзенең язучылык эшчәнлеге турында балаларга гади сүзләр белән бик матур итеп сөйләде. Бары тик Совет илендә генә балаларга укырга тулы мөмкинлекләр булуны, партия һәм хөкүмәтнең балалар турында зур кайгыртучанлык күрсәтүләрен әйтеп, укучыларны отличнога укырга чакырды.

Соңыннан концерт булды.

* * *

24 нче мартта Казанның 12 нче номерлы мәктәбендә Шәриф Камалның 30 еллык юбилеена багышланган кичә үткәрелде. Укучылар һәм укытучылар кичәгә килгән язучыны җылы рәвештә котладылар.

Баян Гыйззәтуллин.

Шәриф Камал әсәрләренә сорау зур

Казанның В. И. Ленин исемендәге Үзәк китапханәсендә соңгы вакытта Шәриф Камал әсәрләрен уку бик нык үсте. Китапханәдә аның 75 данәгә якын төрле әсәрләре бар. Бу әсәрләр һәрвакыт кулда—укучыларда йөриләр.

Китапханә Шәриф Камал юбилеена зур, кыска вакыт эчендә бер күргәзмә оештырды.

Китапханәнең библиографик бүлеге әсәрләрнең [illegible] бүлеге тарафыннан [illegible] китап исемлеге төзелде. Февраль аенда китапханә укучылары арасында Шәриф Камал иҗады турында конференция уздырылды.

Юбилей көнендә шәһәр китапханәләренең активы белән берлектә әдәби кичәсе үткәрелә.

* * *

Күренекле татар язучысы Шәриф Камалның әсәрләре Минзәлә районында киң күләмдә укыла. Шәһәр китапханәсендә аның 60 данәдән артык китаплары бар. Укучылар тарафыннан бу китапларга сорау бик зур. Аның „Матур туганда“ дигән китабын 1.500 кеше, „Таң атканда“ һәм „Акчарлаклар“ дигән әсәрләрен 5.000 якын кеше укыды.

Шәһәр китапханәсе Шәриф Камал тормышына һәм иҗадына багышланган күргәзмә оештырды.

Бүген, 29 нчы мартта, кич сәгать 6 да, Галиәсгар Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театрында, татар совет классик язучысы Шәриф Камалның әдәби һәм җәмгыятьчелек эшчәнлегенә 30 ел тулу уңае белән Тантаналы юбилей кичәсе үткәрелә.

Кичәнең программасы:

1. Тантана бүлеге. Ш. Камалның иҗады турында доклад.
2. Ике бүлектән гыйбарәт сәнгать бүлеге. Ш. Камал пьесаларыннан өзекләр күрсәтү һәм концерт.

Хөкүмәт юбилей комиссиясе.

Иң яхшы пьесага конкурс

Узган елның көзендә Татарстан Халык Комиссарлары Советы иң яхшы пьеса өчен конкурс үткәрү турында карар чыгарган иде. Конкурсның срогы шушы елның 1 нче апреленә билгеләнгән иде.

Бер үк вакытта шушындый ук конкурс РСФСР күләмендә дә үткәрелгәнлектән һәм ул конкурска урыннарда үткәрелә торган конкурсларда иң яхшы дип табылган пьесалар да җибәреләсе булганлыктан, Татарстан Халык Комиссарлары Советы үзенең 22 нче марттагы утырышында бу конкурсның срогын 1 нче апрельдән 1 нче сентябрьгә кадәр озайтырга карар бирде.

Татарстанда үткәрелә торган конкурс комиссиясенә төрле урыннардан һәм төрле телләрдә шушы көнгә кадәр 25 ләп пьеса килде. Конкурс комиссиясенә күп кенә авторлардан бу конкурс белән кызыксынулары, аңа катнашу өчен пьесалар язулары турында һәм кайбер иптәшләрдән конкурска ничек катнашу кирәклеген аңлатуны сорап күп кенә хатлар килә.

Мондый хатларга аерым җаваплар бирү белән бергә, конкурс комиссиясе түбәндәгеләрне тагын бер кат аңлатып китүне тиеш тапты. Конкурсларга СССР ның барлык гражданнары катнашырга хаклы. Конкурска теләсә нинди темага, теләсә нинди жанрда (драма, комедия, водевиль һ. б.), СССР халыкларының бер телендә язылган оригиналь драматургик әсәрләр җибәрелергә тиеш.

Авторлар конкурска үзләренең әсәрләрен бер данәдә, машинкада бастырып яки ачык итеп кулдан язып, фамилияләрен куймыйча, бары тик девизларын гына куйган хәлдә җибәрәләр. Кулъязма белән берлектә, тышына шул ук девизны язып ябык конверт җибәрелә. Ул конвертның эчендә девиз иясенең чын исем, фамилиясе, атасының исме, тулы адресы күрсәтелгән булырга тиеш.

Конкурска килгән әсәрләрне укып чыгып ныклап тикшергәннән соң аларга тиешле бәяне бирү өчен тәнкыйтьчеләрдән, театр, әдәбият өлкәсендә эшләүчеләрдән һәм башкалардан торган 10 кешелек жюри оештырылды.

Конкурсның нәтиҗәсе шушы елның 15 нче декабрендә игълан ителәчәк.

Конкурс комиссиясенең җаваплы секретаре *И. Юзиев.*

Алабуга промсовхозы стахановчылары

Алабуга промсовхозының эшчеләре 1940 нчы елда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашу хокукы өчен уңышлы көрәшәләр. Сыер сауучылардан Мөнирә Хаматова һәм Татьяна Бочкарева, бозаулар тәрбияләүче Марфа Салдина иптәшләр күргәзмәгә катнашу өчен кандидат итеп расландылар.

Иптәш Хаматова 1939 нчы елны һәрбер савым сыердан 3.191 литр, иптәш Бочкарева 2.905 литр сөт савып алдылар, иптәш Салдина узган ел бозауларны 100 проценты белән саклап калды.

3.697 КОЛХОЗ УМАРТАЛЫГЫ

Татарстан колхозлары 1940 нчы елгы уңыштан бал сату өчен өлкә умартачылык конторасы белән договор төзиләр. Казан халкын тәэмин итү өчен 250 тоннага якын бал сатып алу планлаштырылды. Колхозлар 40 тонна балны Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә Татарстан павильонында сату өчен җибәрәчәкләр.

Хәзер Татарстан колхозларында 3.697 умарталык бар. Быел колхоз умарталыклары 3.720 гә кадәр җиткерелә. Кечкенә умарталыклар зурайтыла.

Казанның яшь гимнастларының җиңүе

Балаларның гимнастика ярышлары 27 нче мартта тәмам булды.

13—14 яштәге кыз балалар командаларының ярышында беренче урын өчен көрәш нигездә Архангельский, Чиләбе һәм Казан командалары арасында барды. Архангельскийның яхшы итеп хәзерләнгән командасы беренче урынны алды. Чиләбе командасының да чыгышы яхшы булды һәм ул икенче урынны алды. Казан командасы, баллар саны ягыннан бик үк артта калмаса да, өченче урын белән канәгатьләнергә мәҗбүр булды.

Кече яштәге ир балалар командалары арасында казанлылар бик яхшы чыгыш ясадылар һәм беренче урынга чыктылар. Икенче урынны Куйбышев, өченче урынны Киров һәм дүртенче урынны Ижевски командалары алдылар.

Кечкенәләрдән Турченинов һәм Федорова (Казан), Быкова (Архангельский) һәм Баз (Свердловский) иптәшләр иң яхшы күрсәткечләрне биреп, алдынгы урыннарны алдылар.

Ике көн буена барган ярыш нәтиҗәсендә Казан гимнастлары командасы, 659,67 балл җыеп, беренче урынны алды һәм Бөтенсоюз ярышларында катнашачак. Куйбышев командасы үзенең гаять сәләтле булуын күрсәтте һәм икенче урынга чыкты (642,63 балл), Архангельский командасы быел өченче урын белән канәгатьләнде (618,55). Удмуртия АССР ның башкаласы Ижевски шәһәре командасы дүртенче урынны алды (618,01). Аннан соңгы урыннарны Киров, Свердловский, Чиләбе, Уфа, Чебоксар һәм Молотов командалары алдылар.

Алдынгы урыннарны алган командалар һәм аерым гимнастлар бүләкләнде. *Х.*

УРАМНАРНЫ ТӨЗӘТҮГӘ ХӘЗЕРЛЕК

Хезмәт ияләре депутатларының Казан Шәһәр Советы башкарма комитеты быел шәһәрдәге һәм аның тирәсендәге урамнарны, юлларны һәм күперләрне төзекләндерүгә 988 мең сум билгеләде. Шул ук эшләргә төрле предприятиеләр тарафыннан 1 миллион сумнан артык акча тотылачак.

Тукай, Эсперанто урамнарына, Ленин районының Чистай урамына һәм Кремль янында Казанка аркылы салынган күпергә реконструкция ясала. Нәриман урамына янадан 3.600 квадрат метрга таш, 9.528 квадрат метр күләмендәге тротуарларга асфальт җәелә. Дачаларга, пионер лагерьларына барырга, шулай ук агач ташырга уңайлы булсын өчен, Лебяжье урманына 2 километр озынлыкта яңа юл төзелә. Волга буеннан утын, нефть продуктлары һәм башка йөкләр ташыла торган юл төзәтелә. Яңа дамбадан Бакалтайга 1 километр озынлыкта яңа юл салына.

Индивидуаль йортлар төзүгә 500 мең сум кредит

Эшчеләрнең индивидуаль йортлар салуларына ярдәм күрсәтү өчен быел Татарстан Коммуналь банкысыннан 500 мең сум кредит бирелә. Бу кредит Казан җитен комбинаты, Энергокомбинат, 4 нче ясалма каучук заводы, Мехкомбинат, Бондюг заводы, коры сөт заводы, Юллар Идарәсе һәм Татарстанның җирле промышленносте предприятиеләрендә эшләүчеләргә бирeләчәк.

Кредит алу өчен предприятиеләрнең дирекцияләре индивидуаль йортлар салырга теләүчеләрнең исемлекләрен Таткомбанкка тапшырырга тиешләр. Һәрбер йортны салу өчен елга 2 процент белән 5 ел срокка 5 мең сумга кадәр кредит бирелә. Кредит алырга теләүчеләр үз предприятиеләренең дирекцияләренә мөраҗәгать итәргә тиешләр.

СССР СОВНАРКОМЫ ЯНЫНДАГЫ
— ГЛАВЛЕСООХРАНАНЫҢ —
ЛУБЯН УРМАН ТЕХНИКУМЫ
Техникумга хәзерлек курсларына
УКУЧЫЛАР АЛА

Хәзерлек курсларына 15 тән 30 га кадәр яштәге һәм 7 класс күләмендә белемле ирләр һәм хатын-кызлар алыналар.

Хәзерлек курсларында уку срогы 5 ай. Укулар шушы көннәрдә үк башлана.

Укучылар хәзерлек курсларына сынаусыз алыналар.

Курсларга укучылар алуда татарлар һәм азчылык милләт кешеләре алда тотылалар.

Хәзерлек курсларына алынганнарның барлыгына да айга 60 сум стипендия, шулай ук тулай торакта түләүсез урын һәм ятак әйберләре бирелә.

Хәзерлек курсларын уңышлы тәгаллләүчеләр 1940—41 нче уку елы башында техникумның беренче курсына күчереләләр.

Гариза белән бергә, уку йортларына керү өчен сорала торган документлар бирелергә тиеш.

Адрес: Татарстан АССР, Тәкәнеш районы, Лубян Урман техникумы. 551—1

2 нче апрель, кич 6 сәгатьтә В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан Дәүләт университетының 4 нче аудиториясендә университетның физика-математика факультеты гыйльми советының ачык утырышы чакырыла һәм физика-математика фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен иптәш Ш. Г. Хакимов тарафыннан халык алдында

ДИССЕРТАЦИЯ
яклау үткәрелә

Тема: „Бәйләнешле полиномлы өченче тартиптәге линейный дифференциаль тигезләмәләр турында“.

Рәсми оппонентлар: профессор Б. М. Гагаев һәм профессор К. П. Персидский.

Утырышка Казан шәһәре ВУЗ ларының фәнни работниклары чакырылалар. 541—1

Яңа килгән артистларны урнаштыру өчен Татар Дәүләт Опера театрына
бүлмәләр кирәк
Тәкъдимнәр белән Опера театры конторасына мөраҗәгать итәргә. Зур Галактионов урамы, 12. Телефон 29—04. 549—2—2

Колхозның атлар ишек алдыннан
КАРА ТУРЫ БИЯ ЮГАЛДЫ
Атның арткы сул аягы ак бәкәлле. Шул ат табылса, түбәндәге адрес буенча хәбәр ителүе сорала: Чувашстан АССР, Козловский районы, Янгильдинский авыл советы, Карл Маркс исемендәге колхоз. 1—1

Фото-Желатин заводы төзелешенә, монтаж һәм эксплоатация буенча эшләү өчен 6—7 нче РАЗРЯД ЭЛЕКТРОМОНТЕРЛАР КИРӘК. Тору урны бирелә. Казан, Восстание бистәсе, Фото-Желатин заводының кадрлар бүлеге. 474—5—4

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
29 һәм 30 нчы мартта, шулай ук 1 нче апрельдә күңелле комедия ПРЕМЬЕРА
„КУРКЫНЫЧЛЫ СУД“
30 нчы мартта көндез
ЛЕНИН
Талоннар белән кертелми.
Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 7 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ
31 нче мартта Зур театр бинасында
ФАУСТ
Талоннар белән кертелми.
Коллектив рәвештә килү өчен 29—04 телефоны буенча заявкалар алына.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген һәм һәр көн
ФРАНЦУЗЧА КӨРӘШ
(һәр көн 3 пар көрәшә)
һәм зур программа буенча
ЦИРК УЕНЫ
30 нчы мартта
ЗУР ПРОГРАММАДА
КӨНДЕЗГЕ ЦИРК УЕНЫ
Уен көндез 12 дә, кич 8 дә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 1 гә һәм кич 5 тән 11 гә кадәр ачык.

„ЭЛЕКТРО“ КИНО-ТЕАТРЫ
БАЛАЛАР!
31 нче мартка кадәр һәр көн сезнең өчен махсус рәвештә иртәнге сеанслар үткәрелә.
БИЛЕТ БӘЯСЕ 50 ТИЕН.
Кинога коллектив рәвештә килү өчен заявкалар алына.
Дирекция.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 10, 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы, художестволы яңа фильм ЗУР ТОРМЫШ
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8, һәм 10 да.	ИСТРЕБИТЕЛЬЛӘР (Соңгы көннәре)
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 2, 4, 6, 8, 10 да.	ВОЛГА-ВОЛГА
„ЧАТКЫ“ 6, 8, 9-30 да.	ДИПКУРЬЕР СУМКАСЫ
„ПИОНЕР“ 11, 1, 2, 3-30, 5, 6-30, 8 һәм 10 да.	ШӘХСИ ЭШ. Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП
„РОТ-ФРОНТ“ 6, 8, 10 да.	Гроза
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	20 ЕЛ ЭЧЕНДӘ КИНО

„МАТУР ТУГАНДА“

I

Атаклы язучысы Ш. Камал иҗадының иң мактаулы һәм чәчәк ату чоры Бөек Октябрь революциясеннән соң булды. Социалистик революциянең беренче көннәреннән үк Совет власте өчен көрәш байрагы астына баскан һәм 1919 нчы елда коммунистлар партиясе сафына кергән Ш. Камал, үзенең бөтен иҗадын халык интересларына юнәлтә. Реалист язучы үзенең оста каләме белән яңа, якты тормышны һәм илнең чын хуҗаларының көрәшләрен чагылдыра башлый.

Ш. Камал революциядән соң „Таң атканда“, „Ут“, „Козгыннар оясында“, „Томан арты“ кебек татар совет әдәбиятының матур үрнәкләрен бирде. Совет әдәбиятын хәзерге, социалистик эпоха сорауларына җавап бирерлек яхшы, яңа әсәрләр белән баету өстендә күп еллар буенча эшләү нәтиҗәсендә, 1937 нче елда Ш. Камал үзенең „Матур туганда“ исемле романының беренче кисәген бирде. Совет чынбарлыгын чын магнәсе белән социалистик реализм нигезендә чагылдырган бу әсәр Ш. Камалның гына түгел, бәлки бөтен татар совет әдәбиятының зур уңышларыннан берсе булып тора.

II

Үзенең эчтәлеге белән бу әсәр, Советлар илендә гражданнар сугышы бетеп, илнең халык хуҗалыгын аякка бастыру буенча тыныч эшкә күчү чорын (1920—1921 нче еллар) чагылдыра.

1919 нчы елның мартында Москвада ВКП(б) ның VIII нче съезды була. Бу съездда В. И. Лениннең „Авылда эшләү турында“гы доклады тыңлана.

Шул ук елның декабрендә Москвада игенчелек коммуналары һәм авыл хуҗалыгы артельләренең беренче съезды чакырыла. Владимир Ильич ул вакытта Советлар Россиясендә ике меңгә якын коммуна һәм дүрт меңгә якын авыл хуҗалыгы артеле барлыгын, аларга Совет хөкүмәте һәм партиянең көндәлек ярдәм күрсәтүләрен әйтә. Бөек Ленин әнә шул съездда „Авыл хуҗалыгы коммуналарының исеме бик зур исем, ул коммунизм төшенчәсе белән бәйләнгән“, һәм „Әгәр дә коммуналар үзләрендә крестьян хуҗалыкларын яхшырту буенча, чын-чыннан җидди эш алып барылуын практикада күрсәтсәләр, бу бик яхшы—ул вакытта коммунистларның да, коммунистлар партиясенең дә авторитеты һич шиксез күтәрелер“ ди. (Ленин, XXIV том, 581 бит).

Ш. Камалның „Матур туганда“ исемле романында күрсәтелгән Кигәвенле авылы коммунасы нак менә шушы, югарыда күрсәтелгән чорда оеша. Әсәрдәге бөтен вакыйгалар әнә шул елларда бара.

Язучы үзенең әсәрендә иске авылның яңа баштан корылуын, коллектив эш нигезендә яңа юлга басуын һәм шул юлда яңадан-яңа җиңүләргәирешүен күрсәтү белән бергә, яңа кешеләрне, совет кешеләрен һәм аларның үсешләрен күрсәтүне үзенә бурыч итеп куя. Ш. Камал, матур әдәбиятта большевиклар образын бирү кебек зур һәм җаваплы бурычны ала. Һәм ул аны уңышлы рәвештә хәл итеп чыга.

III

Совет матур әдәбиятында уңай типларны, халыкның иң яхшы черталарын һәм тулы характерларын тулы чагылдыручы большевиклар образын бирү, гаять актуаль һәм шуның белән бергә эшләнергә тиеш булган проблемаларның берсе. Ш. Камал үзенең „Матур туганда“ романы белән художество әдәбияты өстенә төшкән бу җаваплы бурычны үтәүдә алга зур адым ясады. Ул 1920—21 нче елларда төрле сыйныфлар һәм группалар арасында барган катлаулы сыйнфи көрәш шартларындагы төзелештә командалык ролен коммунистлар партиясенә, аның чыныккан членнары Мостафа, Каюмнар, Һидият һәм Фәтхиләргә бирә. Үзләренең характерлары белән төрле-төрле булган, ләкин идея юнәлешләре белән бер юлдан баручы бу геройлар эшләре, үзара мөнәсәбәтләре белән, әсәрдә ышандырырлык итеп биреләләр.

Коммунаны оештыручыларның берсе һәм алдынгысы булып әсәрдә гәүдәләнгән Мостафа образы язучы тарафыннан аеруча бер осталык һәм җылылык белән бирелә. Массалар арасыннан чыгып, гражданнар сугышында актив катнашкан Мостафа чын большевик өчен хас булган сизгерлек һәм принципиальлык үрнәкләрен күрсәтә. Интеллигент Әхмәт, Каюмнар һәм Һидиятләрнең йомшаклык күрсәтүләре аркасында коммунага һәм партия сафына үрмәләгән Нагимне Мостафа фаш итә. Ул „Контрреволюция күктән төшми, җирдән, кулаклар, муллалар ягыннан килә...“ ди. Һәм шуның өчен дә үткәне караңгы булган Нагимнең һәрбер адымын, хәрәкәтен сынап, тикшереп тора. Ләкин Нагимнең чын йөзе тиз генә ачылмый. Садыйк Хаҗи һәм Хөснулла кулакларның ышанычлы агенты булган, алар җитәкчелеге астында коммунада корткычлык эшен алып баручы Нагим, күп кенә этлекләр эшләргә өлгерә.

Нагим битлек кигән хәйләкәр дошман. Шулай да аның йөзе ачыла бара. Мостафа Нагим мәсьәләсен партия җыелышына куярга кирәк дип саный. Мостафа үзенең сыйнфи сизгерлеге һәм Нагим өстеннән булган күзәтүләренә таянып җыелышта Нагимне кулак агенты булуда гаепли. Һәм „Мин Нагимне партиядән һәм коммуна членлыгыннан чыгарырга тәкъдим итәм“ ди. Нагим партиядән чыгарыла. Соңрак Нагимнең йөзе бөтенләй ачыла: бандитлар отряды белән булган кораллы сугыш вактында кулга төшкән Әмирҗан кесәсеннән Нагим кулы белән язылган исемлек, коммунистлар һәм комсомоллар исемлеге чыга, Нагим кулга алына.

Кыскасы, Мостафа образы татар совет әдәбиятында большевик образын бирүдә күренекле үрнәк булып тора.

Әсәрдә Каюм образы да шулай ук зур осталык белән бирелгән. Каюм партия члены. Аның лекцияләрен, докладларын масса яратып тыңлый. Халык аны ярата. Ләкин аның Мостафага караганда кайбер йомшак яклары, килешүчәнлек күрсәтү фактлары бар.

Татбашбюро члены Фәтхи, гомеренең күп өлешен ялчылыкта үткәреп, тик Октябрьдән соң гына иркен сулыш алган Халик, коммунистка Мәдинә образлары Совет шартларында кешеләрнең үсә һәм һаман күтәрелә баруларын ачык чагылдырган образлар.

Әсәрнең төп геройларыннан берсе булган Мәдинә образы укучыда үзенә тирән мәхәббәт тудыра. Мәдинәнең тормыш юлы бик гади. Аның ире Нуретдин Сабитов гражданнар сугышы вактында Дутов бандаларына каршы сугышта каты яралана һәм ике атна лазаретта ятканнан соң үлә. Мәдинә сигез яшлек бала белән кала. Нуретдинның үлү хәбәре ишетелгәч „бу йортның язмышы турында авыл халкы, бигрәк тә картлар: „хатын кеше, әлбәттә, бер үзе дөнья көтә алмаячак... Моннан соң билгеле: йорт тузачак, тегеләй дә, болай да тузачак.. хатын-кыз нәрсә ул? Ир белән бергә һәм ир кеше канаты астында булганда гына азмы-күпме тотраклы кеше. Ирсез калдымы—бетте дигән сүз...“ диләр.

Ләкин совет шартларында Мәдинә югалмый. Ире үлгәч ике ел буена хуҗалыгын алып бара. Күп тә үтми Кигәвенледә коммуна оеша. Мәдинә коммунага керә. Партиягә алуларын сорап гариза бирә. Партия җыелышында „ни өчен партиягә керергә телисең?“ дип сорагач: „Мин Совет власте һәм партиягә хезмәт итү теләге белән керәм. Нуретдин Совет власте өчен җанын бирде, мин дә шул юлда җанымны кызганмаячакмын“ ди.

Әсәрдә Халик, Галләметтин, Нәсимә, Һидият кебек гаять тә матур һәм реалистик образлар бар.

„Матур туганда“ романында сыйнфи дошманның хәйләкәрлеге һәм мәкерлелеге оста итеп бирелгән. Совет властена каршы дошман төрле методлар белән көрәшә. Садыйк Хаҗинең улы Әмирҗан үзенең әтисенә: „Большевикларга каршы сугыш барып чыкмады. Чөнки алар эшчеләрне үз якларына тартудан тыш, крестьяннарне дә үз якларына ияртеләр. Хәзер без большевиклар властен сындырып ташлау өчен икенче метод белән эшкә керешәбез. Ул методны без террор ясау дип атыйбыз...“ ди. Һәм ул кораллы отряд туплап авыл саен коммунистларны, авыл активын үтереп йөри, ахырда кулга алына.

„Шәһәрнең центрында дүрт катлы өч йорты, ике зур магазины, өч мең десятинә җире, урманы булган“ Садыйк Хаҗи баштарак: „Менә! әгелчәннәр хәзер нак шулай итеп уратып алганнар. Кар суы белән бергә бу наглэтләр фит! Алла боерса...“ дип „әгелчәннәр көченә“ ышанып йөри. Ләкин совет ныгыганнан-ныгый бара. Садыйк байның күмелгән алтыннарын да табып чыгара башлыйлар.

Әнә шундый көчле сыйнфи көрәш һәм каршылыклар эчендә коммуна хуҗалыгы ныгый, яңа кешеләр чыныга һәм үсә баралар. 1919 нчы елны булган коммуналар съездында Владимир Ильич коммуналар турында болай дигән иде: „Хәзер яшәп килә торган берничә мең коммуналарның һәм артельләрнең һәрберсе крестьяннар арасында коммунистик идеяләрнең һәм карашларның чын рассаднигы булыр һәм гәрчә ул әле зәгыйфь, кечкенә генә үренде булса да, ясалма үренде түгел, парникта үстерелгән түгел, бәлки яңа социалистик стройның чын үрендесе булуын күрсәтүче практик үрнәк булыр“. (Әсәрләр XXIV том, 586 бит). Ш. Камалның „Матур туганда“ романы менә бу „яңа социалистик стройның чын үрендесе“ булган коллектив төзелешнең җиңүен зур художник осталыгы белән күрсәтте. Бу әсәр совет матур әдәбиятында зур урын алып тора.

Хәмит Ярми.

Татарстан тел һәм әдәбият фәнни-тикшерену институтының гыйлми сотрудникы.

Редактор урынбасары И. ҮЗБЕКОВ.
Зам. редактора И. УЗБЕКОВ.